МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.09.2024 Казан ш. № 183

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр нигезендә **боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
24.09.2024 № 183 боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Министрлык тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлеме яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә үлгән дип игълан итү;

2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең банкротлык процедурасын тәмамлавы – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә.

2.3. оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – бюджетка түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

2.4. штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;

2.5. «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау

турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;

2.6. Бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;

2.7. теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип таныла.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

4.1. активлар керү һәм китү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) утырышына кадәрге айның 1 көненә сатып алучылар, тәэмин итүчеләр һәм башка дебиторлар һәм кредиторлар белән исәп-хисапларның инвентаризацион тасвирламасы (ОКУД буенча формасы 0504089);

4.2. Министрлыкның финанс исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында әзерләнгән бухгалтерлык хисабыннан өземтә - Комиссия соравы буенча;

4.3. Министрлыкның юридик бүлеге тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;

4.4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлемен раслаучы яки аны үлгән дип игълан итү фактын раслаучы документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.2 пунктчасында күрсәтелгән, шәхси эшкуар банкрот дип танылган очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның конкурс производствосын тәмамлау яисә мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән гражданин банкрот дип танылган очракта);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – оешманы бетерү белән бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.3 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

штраф яки суд акты рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү турында акт, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта (Тәртипнең 2 пунктының 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта); Par43

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктларында каралган нигез буенча җәзага тартылучыга башкарма документны кайтару белән бәйле рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы-башкаручысы карары (Тәртипнең 2 пунктының 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2.6 пунктчасында күрсәтелгән очракта); Par46

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар (Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта).

5. Түләүгә ышанычсыз дип тану буенча карарны Комиссия рәисе һәм Комиссия әгъзалары составында Комиссия кабул итә. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы икътисад министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) боерыгы белән раслана.

6. Комиссия рәисе:

Комиссия эшенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан Комиссиянең җаваплы секретарен билгели.

Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен министр боерыгы белән билгеләнгән зат башкара.

7. Комиссиянең җаваплы сәркатибе:

- Комиссия эшчәнлеген алып баруны оештыра;

- Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

9. Министрлык бүлеге хисап аеннан соң килүче айның 5 көненә кадәр хезмәт язуы белән Министрлыкның финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенә яисә юридик бүлегенә Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында бәян ителгән фактлар турында мәгълүмат җибәрә.

Министрлыкның финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге хисап аеннан соң килүче айның 10 көненә кадәр хезмәт язуы белән Министрлык Комиссиясенә Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында бәян ителгән фактлар турында мәгълүмат җибәрә.

Министрлыкның юридик бүлеге хисап аеннан соң килүче айның 15 көненә кадәр, финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенең хезмәт язуы нигезендә Министрлыкның финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында белешмәләр тапшыра.

Тәртипнең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тану нигезләрен раслый торган документлар пакеты Министрлыкның финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында белешмә тапшырылганнан соң 5 эш көне эчендә төзелә һәм Комиссиягә карауга җибәрелә.

10. Комиссия тәкъдим ителгән документлар нигезендә, алар Комиссиягә кергән көннән алып 5 эш көне эчендә, ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышта катнашучы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш бирү юлы белән, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча түләтүгә ышанычсыз бурычны тану турындагы мәсьәләне карый. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәл итүче дип санала. Комиссия карары утырышта аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 булса, хокуклы дип санала.

11. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез һәм Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булганда - Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип танырга;

Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез һәм Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда - Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип танымаска. Әлеге карар

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен кабат карауга комачауламый.

12. Комиссия карары Комиссия утырышы үткәрелгәннән соң 5 эш көне эчендә Комиссия утырышының түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган беркетмәсе белән рәсмиләштерелә:

оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта));

салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик зат – салым түләүченең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүдә бурыч барлыкка килгән белешмәләр;

аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн.

Комиссия беркетмәсенә утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары имза сала һәм утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана.

13. Министрлыкның финансларны исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге Комиссия карары кабул ителгән көнне министрга раслау өчен Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча түләтүгә ышанычсыз бурычны тану турында Министрлык боерыгы проектын әзерли.

14. Комиссиянең карары аңа кул куйган көннән алып 5 эш көне дәвамында министр боерыгы белән раслана.

15. Тәртипнең 11 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмәгә утырышта рәислек итүче һәм утырышта булган Комиссия әгъзалары имза сала һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.